# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

**19.11.2018** **№ 208**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә 2018елның 18ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамланугa 1399 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-1193,бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 85,28% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1107(92,79%) кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 86 кеше тавыш бирде, бу 7,2% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә **2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум** узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. «2019 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 300 сум күләмендә үзара салым кертү, алар өчен түләүләр күләме 100 сум тәшкил иткән 1 төркем инвалидлардан, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән риза буласызмы?

1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңа Кырлай авылы Татарстан урамы-200 м; Яшел урамы-220м;

Яңа Иябаш авылы Татарстан урамы-600м, Елга арты тыкрыгы, Татарстан урамы-Үзәк урамы, Үзәк урамы-Елга арты урамы ;

Чиканас авылы Совет урамы-460м, Октябрь урамы-350м;

Өчиле авылы Интернат-110м, Тукай урамы-350м;

Иске Юрт авылы Клуб урамы-214м;

Югары Бирәзә авылы Ленин урамы -215м;Пәшкәү-110м;

Кукчә Бирәзә авылы Тынычлык урамы - 292м, Аркылы урамы - 385м.

2) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Кырлай авылында Ия елгасы яры буенда агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару.

3) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (Яңа Иябаш авылы);

-5 данә (Чиканас, Өчиле, Иске Юрт, Югары Бирәзә, Кукчә-Бирәзә авыллары) мотопомпалар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта акчаны аерым мәсьәләләр буенча Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
Территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
Территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева